Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
Түбән Кондрата авыл җирлеге Советы

Карары

23 апрель 2019 ел № 57/1

Муниципаль вазыйфалар биләүче
затларны һәм муниципаль хезмәткәрләрне
пенсиягә чыгу сәбәпле,бер тапкыр
акчалата бүләкләү турында

«Муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында"гы 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезенләнеп,Муниципаль хезмәт турындагы Татарстан Республикасы кодексына таянып, Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы»муниципаль берәмлеге Уставын исәпкә алып, Чистай муниципаль районы
Түбән Кондрата авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1.Расларга:
Чистай муниципаль районы “ Түбән Кондрата авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен һәрдаим түләнә торган һәм пенсиягә чыгу сәбәпле,бер тапкыр акчалата бүләкләү шартлары турындагы нигезләмә(1нче кушымта).
Чистай муниципаль районы “ Түбән Кондрата авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турында нигезләмә (2 нче кушымта).
2. Әлеге карарны авыл җирлеге халкы күмәк җыела торган урыннарда, игъланнар өчен билгеләнгән стендларда һәм такталарда элеп кую юлы белән халыкка җиткерергә, Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга www.chistopol.tatarstan.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлык, хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кондрата авыл җирлеге башлыгы С. В. Васильев

1 нче кушымта
Чистай муниципаль
районы “Түбән Кондрата авыл
җирлеге”Советының
2019 елның 23 апрелендәге
57/1 нче номерлы
карары белән расланган

**Чистай муниципаль районы “Түбән Кондрата авылы җирлеге” муниципаль берәмлегендә сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен һәрдаим түләнә торган һәм пенсиягә чыгу сәбәпле, бер тапкыр акчалата бүләкләү шартлары турындагы нигезләмә**

1. Чистай муниципаль районы “Түбән Кондрата авылы җирлеге”муниципаль берәмлегендә сайланулывазыйфаизатларыныңһәммуниципальхезмәткәрләренең хезмәт өчен һәрдаим түләнә торган һәм пенсиягә чыгу сәбәпле, бер тапкыр акчалата бүләкләү (алга таба – бер тапкыр акчалата бүләкләү)шартлары турындагы әлеге нигезләмә, «Муниципаль берәмлекнең вәкиләтле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, «Муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында"гы 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә,Чистай муниципаль районы " Түбән Кондрата авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып гамәлгә кертелә.

2. Чистай муниципаль районы “Түбән Кондрата авылы җирлеге”муниципаль берәмлегендә сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен һәрдаим түләнә торган һәм пенсиягә чыгу сәбәпле, бер тапкыр акчалата бүләкләү (алга таба – бер тапкыр акчалата бүләкләү)шартлары турындагы әлеге нигезләмә, «Муниципаль берәмлекнең вәкиләтле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, «Муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында"гы 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә,Чистай муниципаль районы "Түбән Кондрата авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып гамәлгә кертелә.

3. Муниципаль вазыйфаны биләгән затка бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү билгеләгәндә исәпкә алына торган айлык акчалата түләү күләменәтүбәндәгеләр керә:
айлык акчалата бүләкләү;
айлык акчалата түләү.

4. Муниципаль вазыйфа биләгән затның вәкаләтләре түбәндәге нигезләр буенча туктатылган очракта, бер тапкыр бирелә торган бүләкләү түләнми:
- «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"гы Федераль законның 74.1 статьясы нигезендә отставкага җибәрү сәбәпле;
- «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 74 статьясы нигезендә вазыйфасыннан читләштерү аркасында;
- муниципаль вазыйфа биләгән затка карата суд хөкемкарары законлы көченә кергән очракта;
- Россия Федерациясе территориясеннән чыгып, даими яшәү урынын үзгәртү;
- аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга, яисә чит ил дәүләте территориясендә Россия Федерациясе гражданының даими яшәү хокукын раслаучы башка доку-

мент алырга хокуклы, Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашмаган, аның нигезендә, чит ил дәүләте гражданлыгына ия Россия Федерациясе гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы;
- сайлаучылар бәяләмәсе;
- «Коррупциягә каршы көрәш турында"гы 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларын үтәмәгән очракта, аның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату, 2012 елның 3 декабрендәге «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары әйләнешен туры килүен тикшереп тору турында"гы 230-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы «Аерым затларга счетлар ачу һәм аларга ия булуны тыю турындагы һәм Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында акча һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларыннан файдалануны һәм (яки) аларны куллануны тыю турында»;
-«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне үтәмәгән очракта вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату;
- Россия Федерациясе Президентының ышанычын югалтуга бәйле рәвештә вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату;
- гражданнарның турыдан - туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен таләп ителә торган муниципаль хокукый актны бастырып чыгару вакыты бозылган очракта муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату;
-«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 73 статьясындагы 1 өлеше нигезендә кабул ителгән, муниципаль берәмлекнең вәкиләтле органы үз вәкаләтләрен тапшыру турындагы Татарстан Республикасы Законы үз көченә керүгә бәйле рәвештә туктату.

5. Бер тапкыр бирелә торган бүләкләү хезмәт кенәгәсендә билгеләнә һәм бер тапкыр түләнә.Муниципаль вазыйфа биләгәндә яки пенсиягә чыкканнан соң, граждан кабат муниципаль хезмәткә кергәндә һәм муниципаль вазыйфа биләгән затның вәкаләтләрен туктатканда, яки муниципаль хезмәттән азат ителгәндә, тиешле еллар өчен пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган бүләкләү кабат түләнми.

Чистай муниципаль районының "Түбән Кондрата авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә тиешле елларны эшләгән өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү яки дәүләт хезмәте белән пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү алган гражданнарга, муниципаль хезмәт турындагы законнар нигезендә, пенсиягә чыкканда кабат акча түләнми.

6. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турындагы карар Чистай муниципаль районы Түбән Кондрата авыл җирлеге Советы карары белән беррәттән пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә, даими нигездә муниципаль вазыйфа биләгән затның вәкаләтләрен туктату турындагы карар белән раслана..

7. Бер тапкыр бирелә торган бүләкне гамәлгә ашыру өчен, җирле үзидарә органы әлеге Нигезләмә буенча җирле үзидарә башлыгы һәм хисапчы тарафыннан расланган бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү исәп-хисабын әзерли..

8. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү Чистай муниципаль районы Түбән Кондрата авыл җирлеге бюджеты акчаларыннан әлеге Нигезләмәгә таянып башкарыла.

Чистай муниципаль районы
“Түбән Кондрата авылы җирлеге”
муниципаль берәмлегендә сайланулы
вазыйфаи затларының һәм
муниципаль хезмәткәрләренең
хезмәт өчен һәрдаим түләнә
торган һәм пенсиягә чыгу сәбәпле,
бер тапкыр акчалата бүләкләү
шартлары турындагы нигезләмәсенә
Кушымта

Бер тапкыр акчалата бүләкләү күләме

| | |
|---|---|
| Фамилиясе, исеме, атасының исеме | |
| Туган көне | |
| Вазыйфаның исеме | |
| Җирле үзидарә органы исеме | |
| Нигезләмә таянып айлык акчалата тоту күләме (сум) | |
| Муниципаль вазыйфаны биләү вакыты (стажы) | |
| Вәкаләтләр туктатылу датасы | |
| Бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләрнең күләме | |
| Бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкнең гомуми күләме (сум) | |

Җитәкче ______________ __________________________
(имза) (инициалы, фамилиясе)
Хисапчы ______________ __________________________
(имза) (инициалы, фамилиясе)

МП

Кушымта №2
Чистай муниципаль
районы Түбән Кондрата авыл
җирлеге Советының
2019 елның 23 апрелендәге
№ 57/1 карары

**Чистай муниципаль районы "Түбән Кондрата авылы җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәргә, тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештәбер тапкыр акчалата бүләкләү шартлары турындагы нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә Чистай муниципаль районының «Түбән Кондрата авыл җирлеге» муниципаль хезмәткәренә (алга таба-муниципаль хезмәткәр) тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турындагы Татарстан Республикасы Кодексының 27 статьясы нигезендә, Чистай муниципаль районы «Түбән Кондрата авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып гамәлгә кертелә.

2. Муниципаль хезмәткәр пенсиягә чыгу сәбәпле эштән киткәндә,тиешле еллар эшләгән өчен, аның айлык акчалата керемнәре буенча муниципаль хезмәттә бер тапкыр бирелә торган түләүләр күләме җиде тапкыр арттырып түләнә, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турындагы кодекс нигезендә, муниципаль хезмәт стажы булган очракта, тиешле елларны эшләгән өчен пенсия билгеләү муниципаль хезмәтнең һәр киләсе тулы елы өчен өстәмә рәвештә 0,5 акча өстәлә, ләкин муниципаль хезмәткәргә акчалата түләү күләме ун тапкырдан да артмаска тиеш. Муниципаль хезмәт стажы муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәттән азат итү көненә билгеләнә

Әлеге Нигезләмә тиешле еллар аралыгын эшләп, пенсиягә чыгу өчен муниципаль хезмәттән картлык буенча иминият пенсиясен алу хокукын бирә торган яшькә җиткәч, яки вакытыннан алда картлык буенча иминият пенсиясен, шул исәптән инвалидлык буенча иминият пенсиясен билгеләгәндә, «Иминият пенсияләре турында»гы 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен кирәкле муниципаль хезмәт стажы булганда, эштән азат ителәләр.

3. Пенсиягә чыгу сәбәпле, бер тапкыр бирелә торган бүләкләү турындагы карар, муниципаль хезмәткәрне эштән азат итү турында карар белән бер үк вакытта рәсмиләштерелә.

4. Бер тапкыр бирелә торган бүләкләү күләмен билгеләгәндә,муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи оклады,шулай ук айлык һәм башка өстәмә түләүләр исәпкә алына.

5. Бер тапкыр бирелә торган бүләкне гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органы әлеге Нигезләмә буенча, җирле үзидарә башлыгы һәм бухгалтеры тарафыннан расланган, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү исәп-хисапын әзерли.

6. Бер тапкыр бирелә торган бүләкләү хезмәт кенәгәсендә билгеләнә һәм бер тапкыр түләнә. Гражданны тиешле елларны эшләгән өчен пенсиягә чыкканнан соң, муниципаль хезмәткә кергәндә һәм аннан соң,муниципаль хезмәтне туктатканда, бер тапкыр түләнә торган бүләкләү кабат бирелми.

7. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү Чистай муниципаль районы Түбән Кондрата авыл җирлеге бюджеты акчаларыннан әлеге Нигезләмәгә таянып башкарыла.

8. Россия Федерациясе Хезмәт кодексын, «Коррупциягә каршы көрәш турында» гы Федераль законны, муниципаль хезмәт турындагы законнарның хокук бозыпэштән азат ителгән муниципаль хезмәткәрләргә бер тапкыр түләнә торган акча бирелми.

Чистай муниципаль районы
“Түбән Кондрата авылы җирлеге”
муниципаль берәмлегендәмуниципаль
хезмәткәргә, тиешле еллар эшләгән
өчен пенсиягә чыгу белән бәйле
рәвештә бер тапкыр акчалата бүләкләү
шартлары турындагы нигезләмәгә
Кушымта

Муниципаль хезмәттән пенсиягә чыгу сәбәпле
бер тапкыр бирелә торган бүләкләү
күләме

| | |
|---|---|
| Фамилиясе, исеме, атасының исеме | |
| Туган көне | |
| Муниципаль хезмәт вазыйфасының исеме | |
| Җирле үзидарә органы исеме | |
| Акчалата айлык тоту күләме (сум) | |
| Муниципаль хезмәт стажы (тулы ел) | |
| Бер тапкыр бүләкләү өчен, айлык тотып калган акча күләме | |
| Бер тапкыр бирелә торган бүләкнең гомуми күләме (сум) | |

Җитәкче ______________ __________________________
(имза) (инициалы, фамилиясе)

Хисапчы ______________ __________________________
(имза) (инициалы, фамилиясе)